МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.08.2018 г.Казань № 825

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 4 октябрендә 4908 номеры белән теркәлде

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәләре (бүлекләре) җитәкчеләренә, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурслар үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесенә, Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү вәкаләтләре бирелгән оешмаларга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.

3. «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 июнендәге

435 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын, «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 04 февралендәге 61 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгының 1 пунктын, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 июнендәге 435 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Ю.И.Абдреевны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.08.2018 № 825 боерыгы белән расланды

# Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булган Россия Федерациясе гражданнары, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – гражданнар, гражданин) тора, әгәр аларның яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган түбәндәге шартлар булса:

1) авыру, травма алу, яшенә яки инвалид булуына бәйле рәвештә тулысынча яки өлешчә сәләтне яки үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, тормыштагы төп ихтыяҗларны тәэмин итү мөмкинлеген югалту;

2) гаиләдә даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булган инвалид яки инвалидлар, шул исәптән инвалид бала яки инвалид балалар булуы;

3) социаль яраклашуда кыенлыклар кичерүче бала яки балалар (шул исәптән опекада, попечительлектә торучы) булуы;

4) инвалидны, баланы, балаларны карауны (шул исәптән вакытлыча) тәэмин итү мөмкинлеге булмау, шулай ук аларга карата тәрбия булмавы;

5) гаилә эчендә, шул исәптән наркотик яки алкоголь бәйлелегендәге затлар белән, комарлы уеннарга һәвәслеге булган затлар белән, психик тайпылышлардан интегүче затлар белән, низаг булуы, гаиләдә ирексезләү булуы;

6) билгеле бер яшәү урынының булмавы, шул исәптән егерме өч яшенә җитмәгән һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмада тору вакытын тәмамламаган затның;

7) эш һәм яшәү өчен акча булмау;

8) гадәттән тыш хәлләрнең, коралллы милләтара (этникара) низагларның нәтиҗәләре.

Татарстан Республикасында яшәү (тору) урыны буенча теркәлгән гражданинның яки аның законлы вәкиленең язмача яки электрон формада тапшырылган гаризасы яисә аның законлы мәнфәгатьләрендә гражданинның яшәү урыны (тору урыны) буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының республика муниципаль районнарында (шәһәр округларында) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба

– Министрлыкның территориаль органы) яки Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) карамагында торган, Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тануга һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзүгә Министрлык тарафыннан вәкаләт бирелгән оешмага бүтән гражданнарның мөрәҗәгать итүе, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый оешмаларның мөрәҗәгать итүе яисә социаль хезмәтләр күрсәтү турында тапшырылган гариза яки ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында мөрәҗәгать итү социаль хезмәт күрсәтү турында мәсьәләне карау өчен нигез булып тора.

Яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү турындагы шарт билгеле бер яшәү урыны булмаган затларга, шулай ук, законнарда каралган очракларда, балигълык яшенә җитмәгән затларга кагылмый.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар (аларның законлы вәкилләре), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнарның, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең мөрәҗәгать итүе очрагында) тора.

1.4. Әлеге Регламент нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Министрлыкның территориаль органнары исеменнән Министрлык тарафыннан.

Бу вакытта гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасы проектын әзерләүдә хосусый ихтыяҗын билгеләүдә «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурслар үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Учреждение) катнаша, аталган функцияләр аңа йөкләнгән.

2) Гражданнарны тиешенчә балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануга һәм Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзүгә Министрлык тарафыннан вәкаләт бирелгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләре (алга таба – вәкаләтле оешма) тарафыннан. Вәкаләтле оешмаларның исемлекләре әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

1.4.1. Министрлыкның территориаль органнарының, дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешмаларның, Учреждениенең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адреслары турында мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) http://mtsz.tatarstan.ru сайтында «Территориаль органнар һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр» бүлегендә, шулай ук әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада урнаштырылды.

Министрлыкның территориаль органнарында гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның территориаль органының Министрлыкның эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

Вәкаләтле оешмаларда гаризалар кабул итү графигы: тәүлек дәвамында.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакытлары вәкаләтле оешмаларның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрендә билгеләнә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлыкның территориаль органнарында, Учреждениедә, вәкаләтле оешмаларда урнашкан, дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.8, 2.10, 5.1-5.7 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар булырга тиеш;

2) «Интернет» челтәре аша:

«Интернет» челтәрендә Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка, Министрлыкның территориаль органына, Учреждениегә, вәкаләтле оешмага телдән (шәхсән яисә телефон буенча) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Учреждениегә, Министрлыкның территориаль органына, Министрлыкка, вәкаләтле оешмага язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклар гарантиясе турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ законы) (Россия Федерациясе Халык депутатлары корылтае һәм Россия Федерациясе Югары Советы җыелма басмасы, 1992, № 33, 1913 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Балигълык яшенә җитмәгәннәрнең күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 120-ФЗ номерлы федераль закон) («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 28.06.1999, № 26, 3177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 442-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

«Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 1075 номерлы карары РФ Хөкүмәте) («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 27.10.2014, № 43, 5910 ст.);

Дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт хезмәтләре яисә муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле дәүләт йөкләмәсе (заказы) яисә муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырылучы бүтән оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган һәм 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы белән расланган электрон рәвештә тапшырылучы хезмәтләр исемлеге (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 18, 2679 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 159н номерлы РФ Хезмәт министрлыгы боерыгы) (Российская газета, 2014, 16 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданнарны махсус социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасына юллау тәртибен раслау турында» 2014 елның 6 ноябрендәге 870н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 870н номерлы Россия Хезмәт министрлыгы боерыгы) (Российская газета, 2014, 17 декабрь);

«Социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк рәвеше турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым программасы рәвеше турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 874н номерлы Россия Хезмәт министрлыгы боерыгы) (Российская газета, 2015, 12 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аларга ия булуга бәйле рәвештә гражданинга яисә социаль хезмәтләрне алучыга, шул исәптән вакытлыча, стационар социаль хезмәтләр күрсәтүне кире кагу мөмкин булган медицина каршылыклары исемлеген, шулай ук мондый каршылыкларның булуы турында вәкаләтле медицина оешмасы бәяләмәсе рәвешен раслау турында» 2015 елның 29 апрелендәге 216н номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы) (Российская газета, № 130, 2015, 18 июнь);

«Инвалидлар өчен хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемле булу шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга бу вакытта кирәкле ярдәмне күрсәтү

тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 527н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 2015, 18 сентябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201509180024);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республиксы законы (алга таба – 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы) («Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы», 2014, № 12 (II өлеше), 1361 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе (алга таба – 674 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары» җыентыгы, 2012, № 59, 2041 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибе (алга таба – 908 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2014, № 91-92, 2848 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен

раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – 1053 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – 1100 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 23-24, 0785 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – 1101 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 34-35, 1171 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.6. Әлеге регламент максатларында түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү) – гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

социаль хезмәт – гражданинга аның яшәеш шартларын яхшырту һәм (яки) тормышында үзенең төп ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итү буенча аның мөмкинлекләрен арттыру максатларында даими, вакыт-вакыт, бер мәртәбә ярдәм, шул исәптән ашыгыч ярдәм, күрсәтү буенча социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге гамәл яки гамәлләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм

документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»

дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гариза рәвеше 159н номерлы РФ Хезмәт министрлыгы боерыгы белән расланган.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү | 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 7 ст. 2 өл. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органның (оешманың) аталышы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтен алучының яшәү урыны (тору урыны) буенча Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) исеменнән | 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 7 ст. 2 өл.;<br>908 номерлы Тәртипнең 3 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы<br>Гражданнарны тиешенчә балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануга һәм Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзүгә Министрлык тарафыннан вәкаләт бирелгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләре (исемлеге 1 нче кушымтада) | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:<br>гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм аңа социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын (алга таба – СХКХП) бирү;<br>гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту | 175-ФЗ номерлы федераль законның 15 ст. 2 өл. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яки социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар гариза тапшырылган датадан башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.<br>Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.<br>Социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү һәм гражданинга бирү гариза тапшырган көннән башлап ун эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла. | 422-ФЗ номерлы федераль законның 15 ст. 2 өл.<br>442-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст. 4 өл.; |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | Ашыгыч социаль хезмәтләрне күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасы төзелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган | 442-ФЗ номерлы федераль законның 21 ст. 2 өл. |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 159н номерлы РФ Хезмәт министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча гариза.<br>Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 2 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | РФ Хезмәт министрлыгының 159н номерлы боерыгы;<br>442-ФЗ номерлы федераль законның 15, 16, 31 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>1053 номерлы Тәртипнең 1.4.3, 3.5.2, 3.5.3 пунктлары |
| | Картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларда стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 3 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра.<br><br>Психоневрология интернатларында стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 4 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>870н номерлы Россия Хезмәт министрлыгы боерыгының 5, 6 пунктлары;<br>1110 номерлы Тәртипнең 1.1.2-1.1.4 пунктлары, 2.2.2 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | | 216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Акылы артта калган балалар өчен балаларның интернат-йортларда, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортларда стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 5 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.;<br>3185-1 номерлы РФ законының 41 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>1110 номерлы Тәртипнең 1.1.2-1.1.4 пунктлары, 3.2.2 пункты;<br>216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 6 нчы кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.;<br>3185-1 номерлы РФ законының 42 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен махсуслаштырылган | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.; |

| | | |
|---|---|---|
| | учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре) стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 7 нче кышмтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 181-ФЗ номерлы федераль законның 11 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>1100 номерлы Тәртипнең 1.1.2-1.1.4 пунктлары, 5.2.1, 5.2.3 пунктлары;<br>216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 8 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.;<br>120-ФЗ номерлы федераль законның 13 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 9 нчы кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 11, 15, 16, 31 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары;<br>1100 номерлы Тәртипнең 1.1.2-1.1.4 пунктлары, 7.2.2 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | | 216н номерлы РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы |
| | Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымтсационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә шушы Регламентка 10 нчы кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 15, 16, 31 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; 1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары; 1101 номерлы Тәртипнең 1 бүлеге, 2.2.2 пункты |
| | Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 11 нче кушымтадагы исемлек нигезендәге документларны да тапшыра. | 442-ФЗ номерлы федераль законның 15, 16, 31 ст.; 181-ФЗ номерлы федераль законның 11 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; 1075 номерлы РФ Хөкүмәте карарының 4, 5 пунктлары; 1101 номерлы Тәртипнең 1 бүлеге, 3.2.2, 3.2.4 пунктлары |
| | Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче шушы Регламентка 12 нче кушымтадагы исемлек | 442-ФЗ номерлы федераль законның 15, 16, 31 ст.; 181-ФЗ номерлы федераль законның 11 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; 1101 номерлы Тәртипнең 1 бүлеге; |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендәге документларны да тапшыра. | |
| | Документларның күчермәләре, әгәр дә алар Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булсалар, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла, Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты тарафыннан таныклана.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә дә тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән;<br>почта аша җибәреп.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | 442-ФЗ номерлы федераль законның 15, 16, 31 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>1053 номерлы Тәртипнең 1.4.3, 3.5.1 пунктлары |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен документлар ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша алына, түбәндәге рәвешләрдә:<br>шушы Регламентның 13 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрендә өйдә социаль ярдәм күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 14 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларда стационар социаль хезмәт | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 ст. 1 өл. 2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 15 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, психоневрология интернатларында стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 16 нчы кушымтасына туры китереп, акылы артта калган балалар өчен интернат-йортларда, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортларда стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 17 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең тернәкләндерү бүлекләрендә стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 18 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре) стационар социаль хезмәт күрсәтү;<br>шушы Регламентның 19 нчы кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 20 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга | |

| | | |
|---|---|---|
| | социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә ярымстационар социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 21 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә ярымстационар социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентка 22 нче кушымтадагы исемлеккә туры китереп, сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәкләрендә ярымстационар социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә;<br>шушы Регламентның 23 нче кушымтасындагы исемлеккә туры китереп, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә.<br>Мөрәҗәгать итүче үзенең ихтыяры белән Министрлыкның территориаль органына шушы пунктта күрсәтелгән документларны, мөмкинлеге булган очракта, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә дә тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән;<br>почта аша җибәреп.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул | |

| | | |
|---|---|---|
| | исэптэн «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Югарыда күрсәтелгән документлар шушы Регламентка 13-23 нче кушымталарда күрсәтелгән оешмаларга һәм учреждениеләргә тиешенчә федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларында (норматив актларында) билгеләнгән ысуллар белән алынырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.<br>Министрлыкның территориаль органы, вәкаләтле оешма мөрәҗәгать итүчедән таләп итәргә хокуклы түгел:<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль | |

| | | |
|---|---|---|
| | башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;<br>(Егерме икенче-егерме алтынчы абзацлар 2018 елның 18 октябреннән үз көченә керә)<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълъматлар үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкалэтле оешмасы җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) әлеге Регламентның 1.3 пункты нигезендә гариза бирүче булып тормаучы затның мөрәҗәгать итүе;<br>2) әлеге Регламентның 2.5 п. күрсәтелгән, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүдә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле тиешле формадагы документларның (документларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәләренең) бөтенләй яки тулы күләмдә тапшырылмавы;<br>3) гамәлдәге сроклары беткән документлар (документларның күчермәләрен) һәм мәгълүматлар тапшыру, документларда (документларның күчермәләрендә) билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган һәм төзәтмәләр кертелгән урыннар булу | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1) төгәл булмаган мәгълүматлар тапшыру, гамәлдәге срогы беткән документлар һәм мәгълүматлар тапшыру;<br>2) гражданинда аның яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган шартларның булмавы;<br>3) социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган медицина каршылыкларының ачыклануы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр билгеләнмәгән | 908 номерлы Тәртипнең 13 п. |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 210-ФЗ номерлы федераль законның 8 ст. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен кабул итүне көтүдә чират билгеләнмәгән. | 601 номерлы РФ Президенты указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Социаль хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон рәвештә җибәрелгән, гаризаны теркәү гариза килгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм | Дәүләт хезмәте янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле булган мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларның (кресло-колясалардан һәм сукырларны йөртүче этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп керүен оештыру максатларында, алар өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>а) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектка (бинага, бүлмәгә) каршылыксыз үтеп керү өчен шартлар; | 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 ст., 15 ст.;<br>527н номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| рәсмиләштерүгә карата таләпләр | б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлар (биналар, бүлмәләр) урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук мондый объектларга керү һәм чыгу мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;<br>в) күрү функциясе буенча һәм мөстәкыйль хәрәкәт итүдә тотрыклы бозылышлары булган инвалидларны озатып йөрү;<br>г) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга (биналарга, бүлмәләргә) инвалидларның каршылыкларсыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүматларны тиешенчә урнаштыру, – аларның торышындагы чикләмәләрне исәпкә алып;<br>д) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;<br>е) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>ж) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга (биналарга, бүлмәләргә) сукырларны йөртүче этне кертү, – Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта;<br>з) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтен күрсәтү өчен комачау итүче каршылыкларны җиңәргә ярдәм итү.<br>Бинаны инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча җайлаштыруы мөмкин булмаса, дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында аңа гариза бирү урынына килү мөмкинлеге тәэмин ителә, мөмкинлек булганда, гаризаны кабул итү эше дистанцион тәртиптә гамәлгә ашырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламент бозылу очракларына карата нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның территориаль органы белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны: | 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 ст.;<br>527н номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар турыдан-туры тапшырылганда, – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>әгәр гариза белән документлар-ның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документ-лар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консульта-цияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмә-тен күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүенең озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функ-цияләрнең) бердәм порталыннан http://www.gosuslugi.ru, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан https://uslugi.tatarstan.ru алынырга мөмкин | |
| 2.16. Электрон | Гариза һәм документлар (доку- | 63-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | ментларның күчермәләре) дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/) аша җибәрелергә мөмкин | федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 ст. |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаны һәм тапшырылган документларны карау, дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаны (мөрәҗәгатьне) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булу турында карар кабул итү өчен кирәкле, теркәлгән документлары (документларның күчермәләре) белән кабул итү һәм теркәү яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы буенча тапшырылган һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (тапшырылган) документларны (мәгълүматларны) әлеге Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килү-килмәве буенча карау: гражданинның яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган шартлар булуын (булмавын) билгеләү;

5) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яки социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү;

6) гражданинның социаль хезмәтләргә хосусый ихтыяҗы булуын билгеләү, социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын (алга таба – СХКХП) төзү һәм гражданинга бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-

схема әлеге Регламентның 24 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон буенча, язмача почта буенча һәм (яки) электрон почта ярдәмендә яшәгән урыны (торган урыны) буенча Министрлыкның территориаль органына яки вәкаләтле оешмага консультация алу өчен мөрәҗәгать итә. Консультация алу өчен документларның күчермәләре электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә мөмкин.

Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүне консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаны һәм тапшырылган документларны карау, дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаны (мөрәҗәгатьне) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булу турында карар кабул итү өчен кирәкле, теркәлгән документлары (документларның күчермәләре) белән кабул итү һәм теркәү яисә гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыра.

Гаризада (мөрәҗәгатьтә) күрсәтелгән, социаль хезмәт күрсәтүдә мохтаҗлык булуны билгели торган шартлар булуын раслаучы документлар (документларның күчермәләре) гариза белән берлектә гражданин (аның законлы вәкиле) тарафыннан тапшырыла, ә аның мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта, – бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү артыннан мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш.

Гариза һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта буенча җибәрелергә мөмкин.

Электрон почта аша җибәрелә торган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана һәм Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) мәгълүматны электрон тапшыру җайланмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы ярдәмендә тапшырыла.

Почта аша яки электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль

хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) гомуми тәртиптә карала.

3.3.2. Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече гаризаны һәм тапшырылган документларны (документларның күчермәләрен) гражданин (законлы вәкил) мөрәҗәгать иткән яисә аның мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар мөрәҗәгать иткән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән көнне тикшерә.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә саналган документлар категориясенә караучы документлар (документларның күчермәләре) тапшырылмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) вәкиле социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән көнне гражданинга (законлы вәкилгә), бүтән гражданинга, дәүләт органына, җирле үзидарә органына, иҗтимагый берләшмәгә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм гаризаны һәм (яки) документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, гаризаны һәм (яки) документларны кайтарып бирә.

Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдәнбаш тарту нигезләре булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын (СХКХП) төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаларны теркәүгә алу журналында (алга таба – гаризаларны теркәү журналы) гаризаны терки. Гаризаларны теркәүгә алу журналының рәвеше әлеге Регламентның 25 нче кушымтасында күрсәтелде;

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), бүтән гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны теркәү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамгалап, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында язу тапшыра, ә гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) почта аша яки Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), бүтән гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында хәбәрләмә җибәрә;

гаризаны һәм тапшырылган документларны Учреждениегә тапшыра (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына килгәндә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар

мөрәҗәгать итүчедән (законлы вәкилдән), бүтән гражданнардан, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен), баш тарту нигезләрен күрсәтеп, теркәмичә кайтарып бирү;

гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, гаризаны теркәү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамга белән бирелгән язу яки гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында хәбәрләмә;

Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына килгәндә).

3.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәтләрен яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Гражданин (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тарафыннан тапшырылган документларда һәм мәгълүматларда төгәлсезлекләр булган очракта, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә саналган документлар категориясенә караучы документлардан тыш, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар Учреждение (вәкаләтле оешма) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Мәгълүматлар тапшыру турында гарызнамәләр административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгече Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) мәгълүматларны гарызнамә сорала торган мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органының яки җирле үзидарә органының ведомство буйсынуында торган оешмага килгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә бирә.

Тапшырылган мәгълүматлар административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тарафыннан үз инициативасы нигезендә тапшырылган һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (тапшырылган) документларны (документларның күчермәләрен) Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан карау

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле

үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылган, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (тапшырылган) гаризаны, документларны (документларның күчермәләрен) карый һәм аларда күрсәтелгән мәгълүматларны «Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – мәгълүмат системасы) «Татарстан Республикасында халыкка социальхезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» кече системасына кертә;

документларны (документларның күчермәләрен) өйрәнә һәм дәүләт хезмәте алучының яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган шартлар булуын раслау, социаль хезмәтләр алуга медицина каршылыкларының булуын (булмавын), тапшырылган мәгълүматларның төгәллеген, документларның һәм мәгълүматларның гамәлдәге срогын ачыклау өчен кирәкле белешмәләрне анализлый.

Документларны (мәгълүматларны) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигез булуы ачыкланган очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын әзерли (карар формасы 26 нчы кушымтада китерелде);

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында әзерләнгән карар проектын кәгазьгә чыгартып ала;

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмә проектын әзерли;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында әзерләнгән карар проектын һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмә проектын Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Документларны (мәгълүматларны) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләрнең булмавы билгеләнгән очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын әзерли (карар формасы 26 нчы кушымтада китерелде);

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында әзерләнгән карар проектын кәгазьгә чыгартып ала;

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында, СХКХП төзү

датасы һәм урыны турында хәбәрләмә проектын әзерли;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында әзерләнгән карар проектын һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмә проектын Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көннән башлап дүрт эш көне эчендә, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза каралган очрагында кичекмәстән гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында әзерләнгән карар проекты һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмә проекты административ процедураларның нәтиҗәсе булып тора.

3.6. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яки социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү

3.6.1. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директорына) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар (алга таба – карар) кабул итә һәм тиешле карар проектына һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмә проектына кул куя.

Министрлыкның территориаль органы белгече имзаланган карарны һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәрләмәне аларга Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе кул куйган көнне Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кабул иткән очракта, кичекмәстән гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәрләмә;

Министрлыкның территориаль органыннан Учреждениегә җибәрелгән имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәрләмә

3.6.2. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында хәбәрләмәне язмача яки электрон формада гаризада күрсәтелгән почта яки электрон адреска җибәрә. Уңай карар кабул ителгән очракта гражданинга (законлы вәкилгә) бер үк вакытта социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү датасы һәм аны төзү урыны турында да хәбәр ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты һәм хәбәрләмә Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына кабул ителгән карар турында җибәрелгән хәбәрләмә административ процедураның нәтиҗәсе булып тора. Уңай карар кабул ителгән очракта – гражданинга (законлы вәкилгә) бер үк вакытта социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү датасы һәм аны төзү урыны турында да хәбәр итү.

3.7. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар нигезендә гражданинның социаль хезмәтләргә хосусый ихтыяҗын билгеләү, СХКХП төзү һәм гражданинга бирү

3.7.1. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тарафыннан тапшырылган һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган, шул исәптән гражданинның гаилә составын һәм яшәеш шартларын сыйфатлый торган, документлар (документларның күчермәләре) һәм мәгълүматлар нигезендә дәүләт хезмәте алучының социаль хезмәтләр күрсәтүгә хосусый ихтыяҗын билгели.

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә хосусый ихтыяҗны билгеләү нәтиҗәсендә Учреждение (вәкаләтле вәкил) белгече мәгълүмат системасында 874н номерлы РФ Хезмәт министрлыгы боерыгы белән расланган формада ике нөсхәдә СХКХП проектын әзерли. Гражданин (законлы вәкил) СХКХП төзүдә катнашырга хокуклы.

Социаль куркынычлы хәлдә торучы, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган балигълык яшенә җитмәгән затка СХКХП балигълык яшенә җитмәгән затны тернәкләндерү буенча муницпиаль социаль-тернәкләндерү консилиумында эшләнә һәм раслана торган хосусый программаны исәпкә алып төзелә.

СХКХП төзелгәннән соң Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече аның ике

нөсхәсен кәгазьдә карау һәм имза кую өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура шушы Регламентның 3.6.2 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап өч эш көне эчендә башкарыла.

Ике нөсхәдә карау һәм имза кую өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән СХКХП проекты административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.7.2. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) СХКХП карый һәм имзалый һәм аны мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) тапшыруны оештыру өчен Учреждение (вәкаләтле оешма) вәкиленә юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.1 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган һәм Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрелгән ике нөсхәдәге СХКХП административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.7.3. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган ике нөсхәдәге СХКХП алганнан соң Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече дәүләт хезмәте алучыны (законлы вәкилне) СХКХП белән таныштыра, биредә дәүләт хезмәтен алучы (законлы вәкил) үзенең имзасын куя; бер нөсхәне дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә) тапшыра. СХКХП икенче нөсхәсен Учреждение белгече Министрлыкның территориаль органына җибәрә (вәкаләтле оешма белгече дәүләт хезмәте алучының шәхси эшенә тегеп куя).

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.2 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Ике нөсхәдә имзаланган СХКХП, дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә) тапшырылган бер нөсхәсе, ә Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән (вәкаләтле оешма белгече тарафыннан дәүләт хезмәте алучының шәхси эшенә тегеп куелган) икенче нөсхәсе административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.8. Дәүләт хезмәте КФҮ аша, КФҮ читтән торып эшләү урыны аша күрсәтелми.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. СХКХПда техник хата ачыкланган очракта, дәүләт хезмәтен алучы (законлы вәкил) аны бирү гамәлгә ашырылган Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) түбәндәгеләрне тапшыра:

27 нче кушымтага туры китереп, техник хатаны төзәтү турында гариза;

техник хатасы булган, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә) бирелгән СХКХП;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган документлар (документларның күчермәләре).

СХКХП күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза дәүләт хезмәтен алучы

(законлы вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә.

3.9.2. Министрлыкның территориаль органының (вәкаләтле оешманың) документларны карау өчен җаваплы белгече гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) карый.

СХКХПда техник хата булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә) СХКХПда техник хатаның булмавы турында хәбәр итә һәм аңа, гаризаны һәм (яки) документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча адреска яки электрон почта адресына язмача гаризаны һәм (яки) документларны (документларның күчермәләрен) кайтарып бирә.

СХКХПда техник хата булган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында (28 нче кушымта) терки;

дәүләт хезмәте алучыга (законлы вәкилгә), гаризаны теркәү датасы турында тамгалап һәм СХКХП бирү датасы һәм урыны турында күрсәтеп, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында язу тапшыра.

Әгәр СХКХП Министрлыкның территориаль органында расланган булса, территориаль орган белгече гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хата төзәтү турында гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) теркәмичә кайтарып бирү яисә техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү турында теркәү язуы; мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү датасы турында тамгалап һәм СХКХП бирү датасы һәм урыны турында күрсәтеп, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында бирелгән язу; Министрлыкның территориаль органыннан Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) административ процедураларның нәтиҗәсе булып тора.

3.9.3. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында СХКХП төзәтмәләр кертә;

СХКХП ике нөсхәдә кәгазьдә чыгартып ала;

дәүләт хезмәте алучы адресына техник хатаны төзәтү турында хәбәрләмә (алга таба – хәбәрләмә) проектын әзерли;

СХКХП ике нөсхәсен һәм хәбәрләмә проектын имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хата төзәтү турында гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) имзалау өчен җибәрелгән ике нөсхәдәге СХКХП проекты һәм хәбәрләмә проекты административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.9.4. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма

директоры)ике нөсхәдәге СХКХП проектына һәм хәбәрләмә проектына кул куя, аларны Учреждение белгеченә (вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.9.3 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Имзаланган, Министрлыкның территориаль органыннан Учреждениегә (вәкаләтле оешма директорыннан – вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрелгән ике нөсхәдәге СХКХП һәм хәбәрләмә административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.9.5. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече әлеге Регламентның 3.7.3 пунктчасында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәтен алучы (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәсә, Учреждение (вәкаләтле оешма) вәкиле аңа хәбәрләм җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.9.3 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә) тапшырылган СХКХП, ә дәүләт хезмәтен алучы (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәсә, аңа җибәрелгән хәбәрләмә административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Учреждениенең, Министрлыкның территориаль органының, вәкаләтле оешманың белгече (хезмәткәре) тарафыннан Регламентның һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен саклавына һәм үтәвенә агымдагы контроль Учреждениенең, Министрлыкның территориаль органының җитәкчесе, вәкаләтле оешманың директоры тарафыннан тиешенчә әлеге Регламентның нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә тикшерүләр оештыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Территориаль орган җитәкчесенең, вәкаләтле оешма директорының карарлар кабул итүенә агымдагы контрольне оештыру тәртибе һәм формалары Министрлык тарафыннан билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык аппараты бүлегенең әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган һәм Министрлыкның территориаль органының вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә торган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылуына;

гаризаларны һәм документларны (документларның күчермәләрен) карау

нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма), Учреждение эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә түбәндәгеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү хокукына ия:

территориаль орган белгеченең – территориаль орган җитәкчесенә;

учреждение белгеченең – Учреждение җитәкчесенә;

вәкаләтле оешма белгеченең – вәкаләтле оешма җитәкчесенә.

Вәкаләтле оешма, Учреждение җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр территориаль орган җитәкчесенә, территориаль орган җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының тикрешүдә тотучы урынбасары (алга таба – министр урынбасары) исеменә, Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының тикрешүдә тотучы урынбасары кабул иткән карарларга Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр) бирелә.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

әлеге пунктның 3 пунктчасы 2018 елның 18 октябреннән башлап түбәндәге редакциядә бәян ителә:

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма), Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) вазыйфаи заты (хезмәткәре) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән СХКХПда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

(10 пунктча 2018 елның 18 октябреннән гамәлгә керә)

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) вазыйфаи затының (хезмәткәренең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) дәүләт хезмәткәренең (хезмәткәренең), җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль

хезмәтләр порталынан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга (оешмага) яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) яки вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) исеме;

2) гражданинның – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (оешма) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гражданинга язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

(5.6[1] һәм 5.6[2] пунктлары 2018 елның 18 октябреннән үз көченә керә)

5.6.[1]Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен

күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6.[2]Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр

күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы, гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану һәм Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү вәкаләтләре бирелгән оешмаларның исемлеге

| № | Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмасының аталышы | Территориясендә (территорияләрендә) гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану һәм социальхезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча вәкаләтләр гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең (берәмлекләренең) аталышы |
|---|---|---|
| 1 | «Әгерҗе муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ласка» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Әгерҗе муниципаль районы |
| 2 | «Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Забота» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Спас муниципаль районы |
| 3 | «Аксубай муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Мечта» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Аксубай муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы |
| 4 | «Баулы муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Семья» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Баулы муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы |
| 5 | «Бөгелмә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ялкын» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Бөгелмә муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы |

| | | |
|---|---|---|
| 6 | «Чүпрәле муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Теплый дом» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Чүпрәле муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы |
| 7 | «Яшел Үзән муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гнездышко» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Яшел Үзән муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы |
| 8 | «Казан ш.» шәһәр округында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гаврош» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Казан ш. шәһәр округы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы |
| 9 | «Мамадыш муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Надежда» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Мамадыш муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы |
| 10 | «Менделеевск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Камские зори» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Менделеевск муниципаль районы |
| 11 | «Минзәлә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Минзәлә муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Сарман муниципаль районы |
| 12 | «Питрәч муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Шатлык» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Питрәч муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы |
| 13 | «Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Акчарлак» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 14 | «Саба муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Саба муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы |
| 15 | «Түбән Кама муниципаль районында | Түбән Кама муниципаль районы, Зәй |

| | | |
|---|---|---|
| | балалар һәм яшүсмерләр өчен «Балкыш» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | муниципаль районы |
| 16 | «Яр Чаллы ш.» шәһәр округында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Асылташ» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе | Яр Чаллы ш. шәһәр округы, Тукай муниципаль районы |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы, гражданнарны билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану һәм Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү вәкаләтләре бирелгән оешмаларның исемлеге

| № | Социаль хезмәт күрсәтү оешмасының аталышы Татарстан Республикасы | Территориясендә (территорияләрендә) гражданнарны билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану һәм социальхезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча вәкаләтләр гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең (берәмлекләренең) аталышы |
|---|---|---|
| 1 | «Казан шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Милосердие» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе | Казан ш. шәһәр округы, Югары Ослан муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Яшел Үзән муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Перекресток» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе | Яр Чаллы ш. шәһәр округы, Аксубай муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Әгерҗе муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Тукай муниципаль районы |
| 3 | «Бөгелмә муниципаль районы ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Маяк» социаль яраклаштыру үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе | Бөгелмә муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы |

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Гражданинны халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләрне алучының шәхесен таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе <*> | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмәдә күрсәтелүче |
| 3. | Гражданинның сәламәтлеге торышын, ятлар каравына мохтаҗ булуын сыйфатлаучы, үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшенә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен тулысынча яисә өлешчә югалтуын раслаучы медицина документлары <**> | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелүче |
| 4. | Гражданинның, аның гаилә | керемнәрнең булуы | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әгъзаларының «Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә аның җан башына исәпләгәндә уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) | (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | |
| 5. | Мөрәҗәгать итүчене ташламалы категориягә кертүне раслаучы документ күчермәсе <***> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелүче |
| 6. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар <****> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар документлар бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |

------------------------------

<*> - инвалидларга тапшырыла;

<**> - инвалидлыгы булмаган гражданнарга тапшырыла;

<***> - стационар социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1053 номерлы Тәртипнең 3.5 пункты нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла;

<****> - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ

дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданинны картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларда стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе<*> | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмәдә күрсәтелүче |
| 3. | Гражданинның сәламәтлеге торышын, даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булуын сыйфатлаучы, үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшенә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен өлешчә югалтуын раслаучы медицина документлары <**> | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелүче |
| 4. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Административ күзәтчелек билгеләү турында суд карары күчермәсе <***> | суд органнары | законнар нигезендә |
| 6. | Административ күзәтчелек билгеләү турында тамгасы белән, төзәтү учреждениесеннән азат ителү турындагы белешмәнең күчермәсе <***> | төзәтү учреждениесе | законнар нигезендә |
| 7. | Төзәтү учреждениесе хакимияте тарафыннан бирелгән, сайланган яшәү урынына барырга чыгу яисә, килү вакытын күрсәтеп, килү турында күрсәтмә күчермәсе <***> | төзәтү учреждениесе | законнар нигезендә |
| 8. | Гражданинны административ күзәтчелекне гамәлгә ашыру өчен исәпкә кую турында белешмәләр <***> | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 9. | Мөрәҗәгать итүчене ташламалы категориягә кертүне раслаучы документлар <****> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелүче |
| 10. | Гражданинның, аның гаилә әгъзаларының «Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә аның җан башына исәпләгәндә уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә соңгы 12 ай эчендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) <*****> | | |
| 11. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар <******> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар документлар бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |

--------------------------------

<*> - инвалидларга тапшырыла;

<**> - инвалидлыгы булмаган өлкән гражданнарга тапшырыла;

<***> - иректән мәхрүм итү урыннарын чыгарыла торган яисә чыгарылган затлар исәбендәге, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата административ күзәтчелек билгеләнгән гражданнар өчен гариза биргәндә тапшырыла;

<****> - стационар социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1100 номерлы Тәртипнең 2.2.2 пункты нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла;

<*****> - 1100 номерлы Тәртипнең 2.2.2 пунктында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен тапшырылмый;

<******> - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 4 нче кушымта

Гражданинны психоневрология интернатларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе | федераль медик-социальэкспертиза учреждениеләре, медицина оешмалары | белешмәдә күрсәтелүче |
| 3. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| 4. | Опека һәм попечительлек органының гражданинны психоневрология интернатына җибәрү турында табиб-психиатр катнашындагы табиблар комиссиясе бәяләмәсе нигезендә кабул ителгән карары (законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган, үзенең торышы буенча шәхси гариза тапшыруга | опека һәм попечительлек органнары | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сәләтле булмаган социаль хезмәтләр алучылар өчен) | | |
| 5. | Гражданинны эшкә сәләтсез дип тану турында законлы көченә кергән суд карары (эшкә сәләтсез дип танылган социаль хезмәтләр алучылар өчен) | | |
| 6. | Табиб-психиатр катнашындагы табиблар комиссиясенең социаль хезмәтләрне алучыда аның социаль хезмәт күрсәтүнең бүтән стационар учреждениесендә булу мөмкинлеген юкка чыгара торган психик тайпылышларның булуы турында (законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дин танылган социаль хезмәтләр алучылар өчен); аны суд каршында эшкә сәләтсез дип тану мәсьәләсен кую өчен нигезләр булмавы турында (эшкә сәләтле соцаль хезмәтләр алучы өчен) белешмәләрне үз эченә алган бәяләмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә |
| 7. | Социаль хезмәтләр алучыны эшкә сәләтсез дип тану турында суд карары күчермәсе <*> | суд органнары | суд органы карарында күрсәтелүче |
| 8. | Опека һәм попечительлек органының элек билгеләнгән опекунны вазыйфаларын үтәүдән азат итү турында акты <**> | опека һәм попечительлек органнары | законнар нигезендә |
| 9. | Мөрәҗәгать итүчене ташламалы категориягә кертүне раслаучы документ | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар | билгеләнгән үрнәктәге документта |

| | күчермәсе <***> | һәм комиссияләр | күрсәтелүче |
|---|---|---|---|
| 10. | Гражданин белән берлектә аның яшәгән урыны буенча теркәлгән затлар турында белешмәләрне үз эченә алучы документ <****> | торак-эксплуатация оешмалары | 30 көн |
| 11. | Гражданинның, аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә аның җан башына исәпләгәндә уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә соңгы 12 ай эчендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) <*****> | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |
| 12. | Социаль хезмәтләрне алучының законлы вәкиленең статусын һәм вәкаләтләрен раслаучы документларның күчермәләре <******> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар документлар бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |

--------------------------------

<*> - эшкә сәләтсез гражданнар өчен тапшырыла;

<**> - билгеләнгән опекунга ия булган, эшкә сәләтсез гражданнар өчен тапшырыла;

<***> - стационар социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1100 номерлы Тәртипнең 3.2.2 пункты нигезендә бушлай нигездә социаль

хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла;

<****> - 1100 номерлы Тәртипнең 3.2.2 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен тапшырылмый;

<*****> - 1100 номерлы Тәртипнең 3.2.2 пунктында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен тапшырылмый;

<******> - гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ
дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең
хосусый программасын төзү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 5 нче кушымта

Гражданинны акылы артта калган балалар өчен балалар интернат-йортларында, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Бирелгән көненнән башлап документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмәдә күрсәтелүче |
| 3. | Инвалид баланы тернәкләндерү буенча хосусый программа күчермәсе (2011 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасында ХТП эшләнгән һәм тапшырылган яисә Россия Федерациясенең башка субъектына эшләнгән һәм тапшырылган инвалид балалар өчен) яисә елның гыйнварыннан башлап Россия Федерациясенең башка субъектында эшләнгән һәм тапшырылган, инвалид баланы тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалид баланы тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хосусый программа | | тәмамланганчыга кадәр |
| 4. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | медицина оешмалары | законнар нигезендә |
| 5. | 4 яшьтән 18 яшькәчә кадәрге балалар өчен балигълык яшенә җитмәгән затның акылы артта калган балалар өчен балалар йорты-интернатында яраклаклаштырылган белем бирү программасын үзләштерү мөмкинлеге һәм (яки) зарурлыгы турында мәгълүматларны үз эченә алган психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (балалар йорты-интернатында физик кимчелекләре булган) | Республика яисә муниципаль психологик-медик-педагогик комиссия (консультация) | 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге чор торышына |
| 6. | Опека һәм попечительлек органыннан балага торак урын беркетелүе турында яисә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениесендә торуы тәмамланганнан соң чираттан тыш торак биреләчәге турында акт <*> | опека һәм попечительлек органы | социаль хезмәтләр күрсәтелә башлаганчыга кадәр |
| 7. | Социаль хезмәтләр алучының законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы, статусын һәм вәкаләтләрен раслаучы документлар: | | |
| 7.1 | шәхес таныклаучы документ | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7.2 | опека һәм попечительлек органының опекун яисә попечитель билгеләү турында (опекун статусын алу турында) карары (акты) яисә ата-аналык хокукында чикләү яисә ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында, ата-ананы билгесез рәвештә юкка чыккан, вафат булган, эшкә сәләтсез дип тану турында законлы көченә кергән суд карары | опека һәм попечительлек органы, суд органнары | опека һәм попечительлек органы яисә суд карарында күрсәтелүче |
| 7.3 | опекун яисә попечитель вазыйфаларын башкаручы оешма җитәкчесе тарафыннан бирелгән ышанычнамә<**> | опекун яисә попечитель вазыйфаларын башкаручы оешма | ышанычнамәдә күрсәтелүче |
| 8. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |

<*> - ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга тапшырыла.

<**> - юридик затлар исәбендәге, законлы вәкил исеменнән гамәл кылучы вазыйфаи затка тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

Гражданинны инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләрне алучының шәхесен таныклаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклаучы документ күчермәсе <*> | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 3. | Инвалид баланы тернәкләндерү буенча хосусый программа күчермәсе (2011 елның 30 октябренә кадәр Татарстан Республикасында ХТП эшләнгән һәм тапшырылган яисә Россия Федерациясенең башка субъектына эшләнгән һәм тапшырылган инвалидлар (инвалид балалар өчен) яисә 2016 елның 01 гыйнварыннан башлап | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең хосусый программасында яисә инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасында билгеләнгән, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Россия Федерациясенең башка субъектында эшләнгән һәм тапшырылган, инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү яисә абилитацияләү буенча хосусый программа<**> | | социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү чараларын үткәрүгә мохтаҗ булу турында бәяләмәне үтәү чоры тәмамланганчыга кадәр |
| 4. | Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәт итү, чирләү, травма алу, яшькә бәйле рәвештә яшәү өчен кирәкле төп ихтыяҗларны тәэмин итү сәләтен өлешчә югалтуны раслаучы медицина документлары <***> | медицина оешмалары | медицина документларында күрсәтелүче |
| 5. | Стационар социаль хезмәтләр алу өчен медицина каршылыклары булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| Гражданинны социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла: | | | |
| 6. | Мөрәҗәгать итүчене ташламалы категориягә кертүне раслаучы документ күчермәсе <****> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелүче |
| 7. | Гражданинның, аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның | керемнәрнең булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 18 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә аның җан башына исәпләгәндә уртача keremен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә соңгы 12 ай эчендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) <*****> | | |
| 8. | Инвалид баланың законлы вәкиленең шәхесен, хокукларын таныклаучы документ күчермәсе (паспорт яисә балага опекун, попечительлек билгеләү турында, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карар) <******> | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнар нигезендә |
| 9. | Инвалид баланың мәнфәгатьләрен күрсәтү һәм яклау буенча билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә күчермәсе <*******> | Россия Федерациясе Граждан кодексының 185.1 статьясында һәм Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 53 статьясында күрсәтелгән нотариаль контора яисә оешма һәм учреждениеләр | ышанычнамәдә күрсәтелүче |
| 10. | Вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы документлар <********> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар документлар бирергә вәкаләтле органнары (оешмалар) | законнар нигезендә |

------------------------------
<*> - балигълык яшенә җитмәгәннәр мохтаҗ дип танылганда тапшырыла;
<**> - инвалидлар (инвалид балалар) өчен тапшырыла;

<***> - халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлегендә социаль хезмәтләр алуга килгән, инвалидлыгы булмаган өлкән гражданнар өчен тапшырыла;

<****> - стационар социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1100 номерлы Тәртипнең 5.2.3 пунктының «а«-»д» пунктчалары нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла;

<*****> - 1100 номерлы Тәртипнең 5.2.3 пунктының «а»-«е» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен тапшырылмый;

<******> - инвалид баланы озата йөрүче, аның законлы вәкиле булган зат өчен тапшырыла;

<*******> - инвалид баланы озата йөрүче, аның законлы вәкиле исеменнән гамәл кылучы зат өчен тапшырыла;

<********> - гариза вәкил тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Гражданинны социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Балигълык яшенә җитмәгәннәрнең күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органы яисә учреждениесе вазыйфаи затының үтенеч язуы | опека һәм попечительлек органы, эчке эшләр органы, сәламәтлек саклау идарәсе органы, мәгариф идарәсе органы, яшьләр эшләре буенча орган | дәүләт хезмәтен алганчыга кадәр |
| 2. | Балигълык яшенә җитмәгән баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) язмача гаризасы | - | дәүләт хезмәтен алганчыга кадәр |
| 3. | Ата-ананың (законлы вәкилләрнең) паспорт күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 4. | Гражданинның Россия Федерациясе территориясендә яшәү хокукын раслаучы документ күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 5. | Балигълык яшенә җитмәгән баланың паспорт күчермәсе (14 яшьтән өлкәнрәк | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | балалар өчен) | министрлыгының территориаль органнары | |
| 6. | Баланың туу турындагы таныклыгы күчермәсе (14 яшьтән кечерә булган яисә паспорты булмаган балалар өчен) | гражданлык хәле актларын теркәү органы | 14 яшенә җиткәнче |
| 7. | Сәламәтлек торышы турында, социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында белешмә | сәламәтлек саклау учреждениесе | 30 көн |
| 8. | Гаилә составы турында белешмә (теркәлү булган очракта) | торак фонды белән идарә итүче оешма | 30 көн |
| 9. | Сәламәтлек саклау учреждениесенең ата-ананы яисә законлы вәкилне (ул бердәнбер) госпитальләштерү зарурлыгы турында белешмә | сәламәтлек саклау учреждениесе | белешмәдә билгеләнгән датага кадәр |
| 10. | Балигълык яшенә җитмәгән баланың шәхси гаризасы (язмача яисә телдән рәвештә) | - | дәүләт хезмәтен алганчыга кадәр |
| 11. | Социаль хезмәт күрсәтү системасына керәүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларыннан, учреждениеләреннән, эчке эшләр органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, балигълык яшенә җитмәгәннәр эше буенча комиссиядән, иҗтимагый берләшмәләрдән опекага, попечениегә мохтаҗ | Социаль хезмәт күрсәтү системасына керәүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары, учреждениеләре, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, | дәүләт хезмәтен алганчыга кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | баланы, инвалидны ачыклау турында белешмәләр; тәрбия (шул исәптән вакытлыча) тәэмин итү мөмкинлеге булмау фактын раслаучы документлар (белешмәләр) | балигълык яшенә җитмәгәннәр эше буенча комиссияләр, иҗтимагый берләшмәләр | |
| 12. | Опека һәм попечительлек органнарыннан бала, инвалид турында опека яисә попечительлек билгеләнүгә мохтаҗлыгын билгеләүче белешмәләр | опека һәм попечительлек органнары | дәүләт хезмәтен алганчыга кадәр |
| 13. | Район, шәһәр бүлеге эчке эшләр оператив кизү тору бүлегенең (идарәсенең), бүтән муниципаль берәмлекнең эчке эшләр (идарәсенең) бүлегенең, бык административ-территориаль берәмлекнең эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең), транспорттагы эчке эшләр бүлегенең (идарәсенең) балигълык яшенә җитмәгән баланы социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен махсуслаштырылган учреждениегә кабул итү зарурлыгы турында акты | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | 1 көн |
| 14. | Балигълык яшенә җитмәгән баланың ата-анасын яисә бүтән законлы вәкилләрен тоткарлау, административ арест, сак астына бикләү, арестка хөкем итү, ирекне чикләү, иректән мәхрүм итү очрагында сораштырып белүне башкаручы затның, тикшерүченең яисә, судья | сораштырып белү, тикшерү башкаручы орган прокуратура; суд | карарда, суд карарында билгеләнгән датага кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | карарының күчермәсе | | |
| 15. | Социаль куркыныч хәлдә торучы балигълык яшенә җитмәгән баланың тернәкләндерү буенча ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумы тарафыннан эшләнгән һәм расланган хосусый программасы күчермәсе | Министрлыкның территориаль органы | балигълык яшенә җитмәгән баланың тернәкләндерү буенча хосусый программасында билгеләнгән датага кадәр |
| 16. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Гражданинны билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль яраклаштыру үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе (булган очракта): | | |
| 1.1. | паспорт | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 1.2. | иреккә чыгарылу турында белешмә | Татарстан Республикасы буенча Җинаятьләрне үтәтү буенча федераль хезмәт идарәсе | документ бирелгән вакыттан башлап вакыты чикләнмичә |
| 2. | Инвалидлык турында белешмә күчермәсе (булган очракта) | федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре | белешмә нигезендә, инвалидлык билгеләнгән чор тәмамланганчыга кадәр |
| 3. | Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итүгә медицина каршылыкларының булмавы турында бәяләмә | вәкаләтле медицина оешмасы | законнар нигезендә |
| 4. | Гражданинны ташламалы категориягә кертүне раслый торган документ күчермәсе <*> | вәкаләтле дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар һәм комиссияләр | билгеләнгән үрнәктәге документта күрсәтелүче |
| 5. | Гражданинның, аның гаилә әгъзаларының «Социаль | керемнәрнең булуы (булмавы) турында | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү өчен җан башына исәпләгәндә уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә аның җан башына исәпләгәндә уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен хисаплау өчен файдаланыла торган, акча рәвешендә соңгы 12 ай эчендә алынган керемнәре булуы (булмавы) турында документлар (белешмәләр) <**> | документлар (белешмәләр) бирү вәкаләте бирелгән органнар (оешмалар) | |
| 6. | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документларның күчермәләре <***> | документларны бирергә вәкаләтле булган дәүләт хакимияте вәкаләтле башкарма органнары, оешмалар | законнар нигезендә |

-------------------------------

<*> - стационар социаль хезмәт күрсәтелүгә чираттан тыш, иң беренче чиратта яисә өстенлекле хокукка ия булган ташламалы категория гражданнары өчен яисә 1100 номерлы Тәртипнең 7.2.2 пунктының «а» пунктчасы нигезендә бушлай нигездә социаль хезмәтләр күрсәтелү хокукына ия булган гражданнар өчен тапшырыла;

<**> - 1100 номерлы Тәртипнең 7.2.2 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категория гражданнары өчен тапшырылмый;

<***> - гариза мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта тапшырыла.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Гражданинны гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә ярымстационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документларны бирүче оешма | Документның гамәлдә булу чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
